УПРАВЛЕНИЕ
ПО ОХРАНЕ И
ИСПОЛЬЗОВАНИЮ
ОБЪЕКТОВ
ЖИВОТНОГО МИРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
ҺӘМ АЛАРДАН
ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ

**Приказ** **Боерык**

11.02.2016 г. Казань № 18-од

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияҗлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне раслау турында

2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршылык күрсәтү" турындагы Федераль канун, 2015 елның 22 декабреннән 650 нче номерлы "Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, дәүләт федераль хезмәте вазифаларын,алмаштыручы һәм башка затлар белән, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияҗлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында"гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы белән тәңгәл килеп **боерам:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияҗлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне расларга.

Документ создан в электронной форме. № 683 от 26.04.2016. Исполнитель: Филиппова О.А.
Страница 8 из 22. Страница создана: 25.04.2016 14:09
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

2. Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлегенең алдынгы консультантына (О.А. Филиппова) Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык белән таныштырырга.

3. Боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе башлыгы урынбасары Ю.Б.Матвеевка тапшырам.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков

11.02.2016 елдан 18-од номерлы
Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм файдалану Идарәсе
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияжлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында Кагыйдәнамә**

1. Бу Кагыйдәнамә Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре, Идарә) белән, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияжлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында, аларга карата яллаучы вәкиле булып Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсе башлыгына ( алга таба – Идарә башлыгы) хәбәр итү тәртибен регламентлаштыра.

2. хәбәр гражданлык хезмәткәре белән, әлеге Кагыйдәмәнең Кушымтасында бирелгән рәвеш буенча, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтияжлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында язмача белдерүнамә (алга таба – белдерүнамә) рәвешендә төзелә һәм Идарә башлыгына юнәлтелә.

3. Идарә башлыгы өч эш көнендә, белдерүнамәне коррупцияне һәм башка хокук бозуларны булдырмау эше буенча җаваплы затка, алдан карау өчен җибәрә( алга таба – җаваплы зат).

4. Белдерүнамәне алдан карау барышында җаваплы зат белдерүнамә биргән дәүләт хезмәткәреннән анда күрсәтелгән шартлар буенча аңлатма алырга хокуклы, билгеләнгән тәртиптә дәүләт әгъзаларына, җирле үзидарә әгъзаларына һәм башка оешмаларга сораулар җибәрергә хокуклы.

5. Белдерүнамәне алдан карау нәтиҗәләре буенча, җаваплы зат мотивлаштырылган йомгак ясый.

Алдан карау барышында алынган, белдерүнамә, йомгак һәм башка материаллар, җаваплы зат белән, кабул иткән көннән алып, җиде эш көнендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендә ихтыяжлар бәрелешен хәл итү буенча Комиссия ( алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырылалар.

Документ создан в электронной форме. № 683 от 26.04.2016. Исполнитель: Филиппова О.А.
Страница 10 из 22. Страница создана: 25.04.2016 14:09
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

6. Бу Кагыйдәнамәнең 4 нче пунктында күрсәтелгән сорауларны юнәлткән очракта, белдерүнамә, йомгак һәм башка материаллар, җаваплы зат белән, Комиссия рәисенә белдерүнамәне алганнан соң 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт Комиссия рәисе белән озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артмаска тиеш.

7. Белдерүнамә, йомгак һәм башка материаллар, Комиссия белән, Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең 2015 елның 2 июленән 84-од номерлы боерыгы белән расланган, "Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендә ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча Комиссия турында Кагыйдәнамә" белән тәңгәл килеп карала.

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, вазифаи бурычларын үтәгәндә, ихтыяжлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә Кушымта

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсе башлыгына

__________________________________

__________________________________

(исем, фамилия, атасының исеме, вазифа)

**Вазифаи бурычларны үтәгәндә, ихтыяжлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксыну килеп чыгу турында**
БЕЛДЕРҮНАМӘ

Минем вазифаи бурычларымны үтәгәндә, ихтыяжлар бәрелешенә китерә торган яки китерергә мөмкин булган, шәхси кызыксынуым килеп чыгу турында хәбәр итәм. (кирәклесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксынуга китерә торган шартлар: ________________________

__________________________________________________________.

Шәхси кызыксыну аркасында тиешенчә башкара алмый торган вазифаи бурычлар:

__________________________________________________________

__________________________________________________________

Ихтыяжлар бәрелешен көйләү яки булдырмау буенча тәкъдим ителгән чаралар:

__________________________________________________________

__________________________________________________________.

Бу белдерүнамәне караган вакытта, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәти тәртип таләпләрен саклау һәм Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану

Документ создан в электронной форме. № 683 от 26.04.2016. Исполнитель: Филиппова О.А.
Страница 12 из 22. Страница создана: 25.04.2016 14:09
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

идарәсендә ихтыяҗлар бәрелешен хәл итү буенча Комиссия утырышында шәхси катнашырга ниятлим /ниятләмим (кирәклене астына сызарга).

«__»__________ 20__ ел ______________________________ ______________________

(белдерүнамә бирүченең имзасы) (имзаны чишү)



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН